| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| 21.03.2022 | | 205-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 713-п номерлы боерыгы белән расланган Начар метеорологик шартлар чорында атмосферага пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 29 июнендәге 713-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 28.10.2020 №1195-п, 11.11.2021 №1225-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Начар метеорологик шартлар чорында атмосферага пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.5.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр бүлеп чыгара торган күчмә булмаган чыганакларны һәм чыгарылган пычраткыч матдәләрне инвентарьлаштыру, аның белешмәләрен төзәткәләү, мондый инвентарьлаштыру һәм төзәткәләү нәтиҗәсендә алынган белешмәләрне документлаштыру һәм саклау тәртибен раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 871 номерлы боерыгы таләпләре нигезендә башкарылган стационар чыганакларга һәм атмосфера һавасына чыгарыла торган пычраткыч матдәләрне инвентарьлаштыру турында хисап, – 1 нөсхәдә.;».

Министр А.В. Шадриков